ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19 12 2025 г. № 1596

2026 елга Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының авыл җирлекләрендә торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртүнең индексын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы «Торак урын милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләүнең күләмен үзгәртүнең иң чик индексларын билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау хакында» 213/пр номерлы боерыгына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2026 елга, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән Түбән Кама муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләрендә күпфатирлы йортларның торак урыннары милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен 8,8 процент күләмендә үзгәртү турында карар кабул итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Г. Парамоновка йөкләргә.

Җитәкче: Р.М. Латыйпов